Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 15 маенда теркәлде, № 2728

**Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе**

(Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе)

БОЕРЫК

22.04.2015 Казан ш. 12-07/19

Иҗтимагый совет турында
нигезләмәне раслау хакында

“Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында иҗтимагый совет турында” 18 ноябрь, 2010 ел, № 906 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе

каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең хокук бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) бу боерыкны дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **И.А.Марченко**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 22 апрель, 2015 ел, № 12-07/19 боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршында Иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) алкогольле һәм

спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә дәүләт контрольлеген тәэмин итү буенча дәүләт сәясәтен булдыруда һәм тормышка ашыруда Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын һәм ирекләрен һәм иҗтимагый берләшмәләрнең хокукларын Россия Федерациясе субъектлары карамагына кертелгән вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасында тормышка ашыру белән бәйле булган, шулай ук куллану базарында бозуларны кисәтү һәм аларны булдырмый калуга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өлкәсендә (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эшчәнлеге өлкәсе) мәсьәләләрне карап тикшерүне хәл итүче Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе (Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе) каршында киңәшмә органы булып тора.

1.2. Иҗтимагый советның составы һәм әгъзалары саны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән раслана.

1.3. Иҗтимагый совет үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) таяна.

1.4. Иҗтимагый советның карарлары – тәкъдим итү характерында.

1.5. Иҗтимагый совет үзенең эшчәнлегенең иҗтимагый башлангычларда хәл итә.

1.6. Иҗтимагый советның эше, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, ихтыярый нигездә, хәбәрдарлык һәм партнерлык принципларында корыла.

1.7. Иҗтимагый совет гражданлык җәмгыяте институтлары, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең үзара кызыксынуы нигезендә үз эшен алып бара.

## 2. Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре

2.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары булып тора:

Россия Федерациясе гражданнарының ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм тормышка ашыруда Россия Федерациясе гражданнары хокукларын һәм ирекләрен һәм иҗтимагый берләшмәләрнең ирекләрен яклау;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге өлкәсенә керүче мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп нигезләрен эшләүгә иҗтимагый һәм һөнәри берләшмәләр вәкилләрен җәлеп итү, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлегенең хәбәрдарлык һәм ачыклык принцибын тормышка ашыру;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатына иҗтимагый контрольлекне көчәйтү, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге

өлкәсендә хәбәрдарлык, законлылык һәм профессионализм принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары булып тора:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге өлкәсендәге мәсьәләләргә кагылышлы норматив-хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан эшләнелә торган дәүләт программалары проектлары буенча фикер алышу;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан карарлар кабул итүдә җәмәгатьчелек фикерен учетка алу механизмын камилләштерү;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең хәбәрдарлыгын үстерү.

2.3. Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары эш нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасында икътисадый, социаль һәм сәяси вәзгыятьтән чыгып үзгәртелергә, аларга өстәмәләр кертелергә мөмкин.

**3. Иҗтимагый совет составы**

3.1. Иҗтимагый совет, гражданнарның, социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның тәкъдимнәре нигезендә, рәистән, рәис урынбасарыннан, секретаре һәм Иҗтимагый совет әгъзаларыннан тора.

Иҗтимагый советның персональ составы Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе тарафыннанраслана.

3.2. Иҗтимагый совет, ихтыярый катнашу нигезендә, 12 кешедән формалаштырыла.

3.3. Иҗтимагый совет составына Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче, 21 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданнары, социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар вәкилләре керергә мөмкин. Шул ук вакытта аларның һөнәри сыйфатлары, шул исәптән Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле булган тиешле белемгә ия булулары, бу өлкәдәге эш тәҗрибәләре исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына, бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлардан тыш, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысын тәшкил иткән санда, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән затлар кертелә.

3.4. Иҗтимагый совет әгъзалары сыйфатында Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары, дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук суд карары нигезендә эшкә сәләтсез дип танылган затлар,

хөкем карарын үтәмәгән яки хөкем карары алынмаган затлар, ике гражданлыкка ия булучы затлар, шулай ук “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында” 4 апрель, 2005 ел, № 32-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән башка затлар була алмый.

3.5. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасары, Иҗтимагый советның беренче утырышында Иҗтимагый совет әгъзаларыннан, аларга Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан яртысыннан артыграгы тавыш биргән очракта, сайлап куела. Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын сайлау турында карар Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсе нигезендә рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет рәисен яки рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү турында мәсьәлә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе мөрәҗәгате нигезендә хәл ителә, шулай ук, аларның шәхсән гаризасы буенча яки Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан биштән бер өлеше тәкъдиме буенча, Иҗтимагый совет тарафыннан карала.

Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыграгы тавыш биргән очракта, карар кабул ителгән булып санала.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

Иҗтимагый совет составыннан чыгуы турында үзе гариза тапшырганда;

Иҗтимагый совет эшендә, сәламәтлеге какшау сәбәпле, катнаша алмаганда, Иҗтимагый совет эшчәнлегеннән читләшкәндә яки башка сәбәпләр аркасында;

үзенә карата чыгарылган суд хөкеме карары законлы көченә кергәндә;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә, үзе эшкә сәләтсез дип танылганда яки хәбәр бирмичә кая да булса киткәндә;

этика нормаларын тупас бозганда – утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының күпчелек тавыш белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Үзенең Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда;

чит дәүләт гражданлыгын (подданство) алганда;

Иҗтимагый совет утырышлары эшендә нигезле сәбәпләрсез системалы төстә (өч тапкырдан артыграк) катнашмаганда;

Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары поручениеләрен нигезле сәбәпләрсез системалы төстә (ике тапкырдан артыграк) үтәмәгәндә;

бу Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән вазыйфага керешкәндә.

3.7. Иҗтимагый советта әгъзалыкны туктату, Иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы нигезендә яки Иҗтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасары күрсәтмәсе нигезендә кабул ителә торган, шулай ук бу Нигезләмәнең 3.6 пунктында күздә тотылган хәлләр килеп чыккан очракта, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе карары нигезендә хәл ителә.

Иҗтимагый совет әгъзасы сәламәтлеге какшау, үзенә карата суд хөкеме карары үз көченә керү, Россия Федерациясе гражданлыгын туктату сәбәпле эшләү мөмкинлеген җуйган очракларда, Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге фактлар турында Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда Иҗтимагый совет рәисе күрсәтмәсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе карары нигезендә туктатып торыла:

Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаепләнгәндә;

административ кулга алу рәвешендә административ җәза билгеләнгәндә;

кандидат сыйфатында дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органы депутатлыгына кандидат вазыйфасына, җирле үзидарә органында сайланулы вазыйфага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлысы яки вәкаләтле вәкиле сыйфатында теркәлгәндә, шулай ук Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кергәндә.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы хокуклы:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе инициативасы буенча үткәрелә торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләр, “Түгәрәк өстәл”ләр дә һ.б.) катнашуга, “Дәүләт сере турында” 21 июль, 1993 ел, № 5485-1 Россия Федерациясе законы нигезендә сакланыла торган мәгълүматлар буенча фикер алышу күздә тотылган чаралардан тыш;

Инициатива күрсәтү тәртибендә Иҗтимагый советка анализга корылган записскалар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләп җибәрүгә;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертүгә;

Иҗтимагый совет утырышына, көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерүдә катнашу өчен чакырылган затларның кандидатуралары буенча, тәкъдимнәр кертүгә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгуга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы бурычлы:

Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан бирелгән поручениеләрне үтәүгә;

бу Нигезләмәдә күздә тотылган Иҗтимагый советның эш тәртибен белүгә һәм үтәүгә;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашуга;

Иҗтимагый совет тарафыннан үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен булдырылган экспертлар, эш төркемнәре, комиссияләр, башка эш органнары эшендә катнашуга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үзенең эшен Иҗтимагый совет рәисе күрсәтмәсе буенча Иҗтимагый совет утырышында расланыла торган планнар һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2. Иҗтимагый советның эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тәкъдимнәре нигезендә хәл ителә.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.4. Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашкан очракта Иҗтимагый совет утырышы, үткәрелде, дип санала. Иҗтимагый совет әгъзасы,  утырышта шәхсән катнашу мөмкинлегенә ия булмаганда, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үзенең тавышын һәм үзенең фикерен язмача, факсимиль элемтә яки электрон почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшыруга хокуклы (бу хакта Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына яисә Иҗтимагый советның җаваплы секретарена алдан хәбәр итеп). Утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзалары исәбенә үз тавышларын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына ышанып тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары өстәлә.

Иҗтимагый совет карарлары күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5.5 Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе, ул югында – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары үткәрә.

5.6. Йөкләнгән максатлары, бурычлары, вәкаләтләре нигезендә кабул ителә торган Иҗтимагый совет карарлары тәкъдим итү характерына ия һәм алар кызыксынулы затлар игътибарына Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә яки Иҗтимагый совет карары буенча башка ысул белән җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый советның эш материаллары “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Иҗтимагый совет сайтына яки Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе сайтындагы “Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет” бүлегенә урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый советның эш планын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый совет раславына тапшыра;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының  көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет тәкъдимнәренә, беркетмәләренә һәм Иҗтимагый советның башка документларына кул куя;

Иҗтимагый совет утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый советка йөкләнгән максатлар һәм бурычларны үтәү кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына поручениеләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән запросларга, рекомендацияләр, тәкъдимнәр, җаваплар, аңлатмалар һәм мөрәҗәгатьләргә кул куя;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне хәл итә.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе рәсми төстә вакытлыча булмаганда, аның функцияләрен үти;

Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисенә раслауга тапшыра;

Иҗтимагый совет рәисе поручениесе нигезендә Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне үти.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы секретаре:

утырышларга материаллар һәм карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый советны үткәрү урыны һәм вакыты, көн тәртибе турында хәбәр бирә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллары белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет белән ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең оештыру буенча берлектә эшләвен тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документлар-техник яктан тәэмин итүне башкара;

Иҗтимагый совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларны үтәүгә контрольлек итә;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында тыңлауга һәм фикер алышуга мәсьәләләр әзерләү өчен эш төркемнәре, экспертлар төркемнәренә һәм башка эш органнарына берләшергә, материаллар әзерләүгә, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән

килештереп, Иҗтимагый совет составына кермәгән белгечләрне җәлеп итәргә мөмкин.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына, Иҗтимагый совет тарафыннан карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматлар һәм бәяләмәләр бирү өчен, башкарма органнар, коммерциясез оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаган мәссакүләм-мәгълүмат чаралары вәкилләре, Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында катнашырга мөмкин.

5.13. Иҗтимагый советның карап тикшерүенә кертелә торган материаллар бу материалларны карап тикшерү күздә тотылган Иҗтимагый совет утырышының билгеләнгән датасына кадәр ун календарь көненнән дә соңга калмыйча Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына тапшырылырга тиеш. Материалларны моннан соңрак срокта тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлеген техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе хәл кыла.